**СОВЕТ БИРЮЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422737, Республика Татарстан, Высокогорский район, п.Бирюлинского з/с, ул. Кольцевая, 33

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БӨРЕЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422737, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Бөреле җәнлек совхозы пос, Божра урамы, 33

Тел./факс 8(84365) 76-5-45, e-mail: Brl.Vsg@tatar.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**21 сентябрендәге 2020 г.** **№ 1**

**Муниципаль берәмлек башлыгын сайлау турында Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Бөреле авыл җирлеге Советы депутатлары составыннан**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Биектау муниципаль районы Бөреле авыл җирлеге Уставының 35 статьясындагы 1 өлешенең 9 пункты, 44 статьясындагы 2 өлеше нигезендә һәм хисап комиссиясенең 2020 елның 21 " сентябрендәге 2 номерлы беркетмәсе нигезендә, Биектау муниципаль районы Бөреле авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1.«Биектау муниципаль районы Бөреле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгын сайлау буенча яшерен тавыш бирү нәтиҗәләрен расларга һәм 8 нче номерлы Бөреле бермандатлы сайлау округы депутаты Баһаветдинов Таһир Хәйдәр улын, Бөреле авыл җирлеге башлыгы һәм Биектау муниципаль районының Бөреле авыл җирлеге Советы рәисе итеп сайларга.

2. Биектау муниципаль районы Бөреле авыл җирлеге Советы муниципаль берәмлек башлыгы вазыйфасына керешү көне

аны Биектау муниципаль районының Бөреле авыл җирлеге Советы депутатлары составыннан сайланган көн дип санарга.

3. «Җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясындагы 1 өлеше һәм Бөреле авыл җирлеге Уставының 43 статьясындагы 5 өлеше нигезендә Баһаветдинов Таһир Хәйдәр улын Биектау муниципаль районы Бөреле авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе итеп билгеләп куярга

4. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ Фәрит Мөхәммәтшин "Бердәм Россия" Бөтенроссия сәяси партиясенең Татарстан төбәк бүлеге сәяси советы утырышын уздырды http://pravo.tatarstan.ru/

Рәислек Итүче Т. Х. Багаутдинов